# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тиган Болак торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 22 октябрендәге 2 номерлы

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тиган Болак торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тиган Болак авыл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндез укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган,МХО да катнашучы гражданнардан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Родники авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Родники авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:/ / pravo. tatarstan .ru)бастырып чыгарырга .

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы Родники
авыл җирлеге башлыгы Е.А. Яковлева